**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

№ 28 «21» 04 2020 ел

2020 елга Аксубай муниципаль районының
консолидацияләнгән бюджеты чыгымнарын
оптимальләштерү программасын раслау турында

2020 елга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджетының баланслылыгын тәэмин итү максатларында:

1. Чыгымнарны оптимизацияләү программасын һәм бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, 2020 елга Аксубай муниципаль районы консолидацияләнгән бюджетының өстәмә бюджеттан тыш чыганакларын эзләү Планын расларга.

2. Авыл җирлекләре башлыкларына, Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләренә, программа чараларын җаваплы башкаручыларга:

2.1. муниципаль программаларны гамәлгә ашырганда, шулай ук Аксубай муниципаль районының норматив хокукый актлары проектларын әзерләгәндә Программа нигезләмәләренә таянып эш итәргә;

2.2. хисап чорыннан соң килүче ай саен, 2020 елның 1 маеннан башлап, 10 числосыннан да соңга калмыйча, Аксубай муниципаль районының Финанс палатасына программага кушымта булып торучы Аксубай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү буенча чаралар Планын үтәү турында отчетлар (алга таба – Чаралар планы) җибәрергә.

3. Мәгариф бүлеге начальнигы С.Ю. Зайцевка, мәдәният бүлеге начальнигы А. С. Тимирясевка, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы Р. К. Канафинга әлеге карарны муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И. И. Моратшинга йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы Башлыгы К. К. Гилманов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫНЫҢ 20__ ЕЛНЫҢ
«__» __________ __НЧЕ НОМЕРЛЫ
КАРАРЫ БЕЛӘН РАСЛАНДЫ

**2020 елга Аксубай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү программасы.**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

2020 елга Аксубай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерүнең әлеге программасы (алга таба – Программа) Аксубай муниципаль районы бюджеты чыгымнарының беренчел юнәлешләрен тәэмин итү һәм Аксубай муниципаль районында финанс тотрыклылыгын саклап калу максатларында бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген арттыруга һәм финанслауны яңадан юнәлтүгә юнәлдерелгән.

Программаны гамәлгә ашыру чорында бюджет чыгымнарын оптимальләштерү өлешендә бюджет сәясәтенең төп приоритетлары булып тора:

1) муниципаль идарәгә чыгымнарны оптимальләштерү;

2) бюджет челтәрен оптимальләштерү һәм берләштерелгән бюджет чыгымнарын оптимальләштерү;

3) муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар системасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

4) Аксубай муниципаль районы бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту;

5) бюджеттан тыш өстәмә чыганаклар эзләү;

6) бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү.

## 2. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты - нефтькә бәяләр, җитештерү күрсәткечләре, икътисадның күп кенә тармакларында продукция эшләп чыгаруның фаразланган кимүе белән бәйле рәвештә, 2020 ел азагына кадәр керемнәрнең кискен акрынаюы шартларында чыгымнарның беренчел юнәлешләрен тормышка ашыруга яшерен резервларны эзләү һәм финанслауны яңадан юнәлтү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1) Аксубай муниципаль районы бюджеты акчаларының нәтиҗәлелеген арттыру резервларын һәм механизмнарын ачыклау;

2) муниципаль идарә секторында бюджет акчаларын һәм муниципаль мөлкәтне файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

3) бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту;

4) бюджетның беренчел булмаган чыгымнарын чикләү һәм кыскарту һәм аларны оптимизацияләү.

Программа чаралары, аларны гамәлгә ашыру ысуллары, Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар әлеге программа кушымтасында тәкъдим ителгән.

## 3. Программаны гамәлгә ашыру механизмы, аны гамәлгә ашыру барышын тикшереп тору

Программаның координаторы - Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - Программаның координаторы).

Программа чараларын гамәлгә ашыручы җаваплы башкаручылар - Аксубай муниципаль районының җирле үзидарә органнары, башкарма комитетның структур бүлекчәләре, муниципаль бюджет һәм казна учреждениеләре,

Программаны тормышка ашыру белән идарә итү, Программаның җаваплы башкаручылары эшчәнлеген гомуми координацияләүне һәм Программаны тормышка ашыру барышын контрольдә тотуны Программаның координаторы башкара.

Программаның координаторы Программа чараларын гамәлгә ашыруны координацияләү һәм тикшереп тору кысаларында түбәндәге чараларның үтәлешен тәэмин итә:

1) Программаны үтәү өчен кирәкле норматив хокукый актлар проектларын билгеләнгән тәртиптә әзерлиләр һәм килештерә;

2) программаны тормышка ашыру барышын мониторинглауны һәм бәяләүне гамәлгә ашыра;

3) программага кирәкле үзгәрешләр кертә;

4) Аксубай муниципаль районы Советының рәсми сайтында программа текстын, шулай ук программаны гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүмат урнаштыруны оештыра.

Программаның җаваплы башкаручылары:

1) Программа чараларын үтәү өчен кирәкле норматив хокукый актлар проектларын билгеләнгән тәртиптә әзерлиләр һәм килештерәләр;

2) программаны гамәлгә ашыруга бәйле куркынычларны минимальләштерү чараларын күрә;

3) Программаны гамәлгә ашыру барышы турында хисап һәм Программаны гамәлгә ашыру барышын мониторинглау һәм бәяләү өчен кирәкле башка соратып алына торган документлар Программа координаторына тапшыра.

## 4. Программаны гамәлгә ашыру тәвәккәлекләре.

Программаны тормышка ашыру тәвәккәллекләре финанс һәм икътисади тотрыксызлык шартларында Аксубай муниципаль районының бюджет системасы эшчәнлегенә йогынты ясый торган кайбер тышкы һәм эчке факторлар барлыкка килүгә бәйле.

Программаны тормышка ашыру белән бәйле түбәндәге тәвәккәллекле төркемнәрен аерып алырга мөмкин:

1. Аксубай муниципаль районының төп макроикътисади күрсәткечләренең тискәре үзгәрүенә бәйле икътисади тәвәккәллекләр – тышкы икътисадый конъюнктура параметрларының начараюын һәм башка төп икътисадый факторлар.

2. Финанс тәвәккәллекләр – үз керемнәре буенча планны үтәмәү, Аксубай муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен тулысынча яки билгеләнгән вакытка үтәмәү куркынычы, республика бюджетыннан бюджетара трансфертларны кыскарту.

3. Хокукый тәвәккәллекләр - федераль һәм республика дәрәҗәсендә бюджет-финанс сәясәтен гамәлгә ашыру алымнарының үзгәрүенә һәм Россия Федерациясенең бюджет һәм салым законнарын үзгәртүгә бәйле тәвәккәллекләр.

4. Оештыру тәвәккәллекләр – идарә кадрларының хаталары, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны дөрес бүлү, бүлекчәләр һәм хезмәткәрләр арасында җайга салынмаган коммуникацияләр булмау, эчке контроль булмау, Программа чараларын вакытында һәм/яки вакытында башкармау.

2020 елга Аксубай муниципаль районы
бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү
программасына кушымта

## 2020 елга Аксубай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү буенча чаралар планы

| № т/б | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Реальләштерү вакыты | Максатчан күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткечнең әһәмияте |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | **Салым һәм салым булмаган керемнәрне арттыру буенча чаралар.** | | | | | |
| 1.1. | Салым һәм җыемнарны өстәмә мобилизацияләү, шул исәптән салым базасын киңәйтү хисабына. | Башкарма комитетның икътисад бүлеге, Финанс бюджет Палатасы, авыл җирлекләре башлыклары исемлеге буенча | Даими | Бюджет керемнәрен арттыру | Әйе/юк | Әйе |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2 | Җирле үзидарә органнары тарафыннан салымнар һәм җыемнар буенча бирелә торган салым ташламаларының нәтиҗәлелеген бәяләү, алга таба ташламаларны бетерү / бирү критерийларын катгыйландыру белән / | Башкарма комитетның икътисад бүлеге, Финанс бюджет Палатасы, авыл җирлекләре башлыклары исемлеге буенча | Даими | Бюджет керемнәрен арттыру | Әйе/юк | Әйе |
| 1.3 | Физик затлар керемена салым һәм аның белән бәйле физик затлардан милек салымнарын мобилизацияләү сәбәпләрен анализлау. | Финанс бюджет палатасы, Башкарма комитетның икътисад бүлеге | Даими | Бюджет керемнәрен арттыру | Әйе/юк | Әйе |
| 1.4 | Күләгәдә мәшгульлекне легальләштерү буенча чаралар үткәрү. | Башкарма комитетның икътисад бүлеге. | Даими | Бюджет керемнәрен арттыру | Мең сум | 50 |
| 1.5 | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген оештыру максатларында муниципаль милектәге мөлкәтне файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру. | Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы | Даими | Бюджет керемнәрен арттыру | Мең сум | 2421 |
| 1.6 | Күчемсез мөлкәт объектларын, шул исәптән җир кишәрлекләрен дә кертеп, салым әйләнешенә кертү, шул исәптән: күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматларны төгәлләштерү; | Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы һәм авыл җирлекләре башлыклары исемлеге буенча | Даими | Бюджет керемнәрен арттыру | Мең сум | 100 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күчемсез мөлкәт объектларының дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләрен актуальләштерү; мәгълүмат алмашу кысаларында җир кишәрлекләре һәм башка күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр бирү; муниципаль җир контроле үткәрү. Җир кишәрлекләре һәм башка күчемсез мөлкәт милек хуҗаларын ачыклау һәм аларны салым салуга җәлеп итү, физик затларның җир кишәрлекләренә һәм мөлкәтенә милек хокукын рәсмиләштерүдә ярдәм итү. | | | | | |
| 1.7 | Җирле үзидарә органнары белән муниципаль берәмлектә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, хокук саклау органнары белән керемнәр җыюны арттыруга юнәлдерелгән чараларны үтәү буенча ведомствоара хезмәттәшлекне көчәйтү. | Башкарма комитет, Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 12 нче районара инспекциясе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе (Россия Суд приставлары Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Аксубай район бүлеге) | Даими | Бюджет керемнәрен арттыру | Мең сум | 150 |
| 1.8 | Физик затларның мөлкәт салымнарын мобилизацияләү | Финанс бюджет палатасы, икътисад бүлеге, авыл | 2020 ел | Бюджет керемнәрен | Мең сум | 200 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | буенча чаралар үткәрү. | җирлекләре башлыклары исемлеге буенча | | арттыру | | |
| 1.9 | Аксубай муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетына салым түләүләре буенча бурычларны кимету буенча чаралар үткәрү | Финанс бюджет палатасы, икътисад бүлеге, авыл җирлекләре башлыклары исемлеге буенча | 2020 ел | Консолидацияләнгән бюджетка бурычларны киметү | Мең сум | 250 |
| 2 | **Чыгымнарны оптимальләштерү чаралары.** | | | | | |
| 2.1. | Җирле үзидарә органнары санын арттыруга юл куймау | Районның җирле үзидарә органнары | Даими | 31.12.2019 ҖҮО( җирле үзидарә органнары) хезмәткәрләренең штат берәмлекләре саны | Берәмлек | 105 |
| 2.2. | Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар белән муниципаль районның җирле үзидарә вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле булмаган чыгым йөкләмәләрен үтәмәү, кабул ителгән чыгым йөкләмәләрен анализлау | Финанс бюджет палатасы, район башкарма комитетының структур бүлекчәләре, җирлекләр башкарма комитетлары | Даими | Үтәлгән/ үтәлмәгән | Әйе/юк | Әйе |
| 2.3. | Җирле үзидарә органнарын тотуга чыгымнар нормативларын үтәү | Финанс бюджет палатасы, Контроль-хисап палатасы, бухгалтерлык исәбе буенча бүлекләр, җирлекләр бухгалтерлары | квартал саен | Үтәлгән/ үтәлмәгән | Әйе/юк | Әйе |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.4. | Идарә аппараты автотранспортын тотуга чыгымнарны 5% ка киметү | Финанс бюджет палатасы | 1 июльгә кадәр | Бюджет чыгымнарын киметү | Мең сум | 211,8 |
| 2.5. | Бюджет системасының барлык учреждениеләрендә чиратсыз чыгымнарны 15 % ка киметү | Финанс бюджет палатасы | 1 июльгә кадәр | Бюджет чыгымнарын киметү | Мең сум | 2931,8 |
| 2.6. | Җылылык, энергия ресурсларын куллануны экономияләү | Районның барлык учреждениеләре | Ел ахырына кадәр | Бюджет чыгымнарын киметү | Мең сум | 5351,3 |
| 2.7. | Хезмәткәрләрне дистанцион укытуга күчү белән бәйле рәвештә, командировка чыгымнарын 15 % ка киметү | Районның барлык учреждениеләре | Ел ахырына кадәр | Бюджет чыгымнарын киметү | Мең сум | 463,1 |
| 2.8. | Район муниципаль учреждениеләре мөлкәтен инвентаризацияләү һәм аларны карап тоту өчен нәтиҗәсез чыгымнарны ачыклау | Районның барлык учреждениеләре | Ел ахырына кадәр | Чыгымнарны киметү | Мең сум | 161,4 |
| 2.9. | Муниципаль мәгариф учреждениеләре челтәрен зурайту һәм үзгәртеп кору, шул исәптән: | Башкарма комитетның мәгариф бүлеге | 2020 ел | Чыгымнарны киметү | Мең сум | 300,3 |
| | "Киса балалар бакчасын" МБМБУ бетерү | Башкарма комитетның мәгариф бүлеге | 2020 ел | Чыгымнарны киметү | Мең сум | 300,3 |
| 2.10 | Муниципаль бюджет учреждениеләренең бюджеттан тыш эшчәнлегеннән кергән керемнәр хисабына, шул исәптән муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле кулланудан килгән чыгымнар | Мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге, муниципаль учреждениеләр, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы | Ай саен | Бюджет эффекты (узган ел белән чагыштырганда) | Мең сум | 50 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күләмен арттыру | | | | | |
| 2.11 | Билгеләнгән срокта муниципаль йөкләмәне үтәүгә муниципаль хезмәтләр (эшләр) күләменең тиешле күрсәткечләренә туры килгән күләмдә район бюджетына субсидияләрне кире кайтаруны тәэмин итү | Мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге , район Башкарма комитеты, Финанс бюджет палатасы, муниципаль бюджет учреждениеләре | 2020 елның 15 декабренә кадәр | Үтәлгән/ үтәлмәгән | Мең сум | - |
| 2.12 | Дебитор бурычларын киметү, суд тәртибендә бурычларны түләттерү буенча чаралар барлыкка килү һәм кабул итү сәбәпләрен анализлау | Җирле үзидарә органнары, район башкарма комитетының структур бүлекчәләре, муниципаль учреждениеләр | Даими | Кичектерелгән дебитор бурычларын кыскарту (алдагы ел белән чагыштырганда) | Мең сум | - |
| 2.13 | Аксубай муниципаль районы бюджетының вакыты чыккан кредиторлык бурычы булмавын тәэмин итү | Финанс бюджет палатасы, җирле үзидарә органнары, район башкарма комитетының структур бүлекчәләре, муниципаль учреждениеләр | Даими | Үтәлгән/ үтәлмәгән | Әйе/юк | Әйе |
| 2.14 | Район бюджет учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны үтәүне тәэмин итү | Җирле үзидарә органнары, башкарма комитетның структур бүлекчәләре | Даими | Норматив чыгымнарны үтәү | Әйе/юк | Әйе |
| 2.15 | Бюджет учреждениеләренең матди-техника базасын ныгытуга чыгымнарны оптимизацияләү, процедураларны конкурентлы ысул белән уздыру | Муниципаль бюджет учреждениеләре, икътисад бүлеге | Даими | Чыгымнарны киметү | Мең сум | 281,4 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.16 | Сатып алуларның нигезлелеген, башлангыч (максималь) контрактларның бәяләрен, сатып алына торган товарның комплектлылыгын, аның техник характеристикаларын контрольдә тоту | Муниципаль бюджет учреждениеләре, икътисад бүлеге, җирле үзидарә органнары | Даими | Контрольне гамәлгә ашыру | Мең сум | 150 |
| 2.17 | Агымдагы финанс елына район бюджетын үтәгәндә Россия Федерациясе Бюджет кодексында дефицит күләменә, муниципаль бурыч алулар күләменә, муниципаль бурыч күләменә һәм муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнарына билгеләнгән чикләүләрне үтәү | Финанс бюджет палатасы | Ай саен | Үтәлгән/ үтәлмәгән | Әйе/юк | Әйе |